РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Исполнительный комитет
Чубар-Абдулловского
сельского поселения
Азнакаевского муниципального
района

ул. Советская, д.81, с.Чубар-Абдуллово, 423323

Тел. (8-85592) 38-7-37

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Чубар-Абдул авыл жирлеге
башкарма комитеты

Совет урамы, 81, Чубар-Абдул авылы, 423323

(8-85592) 38-7-37

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от «23» сентября 2019 года № 46

Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22, 56 статьялары, 24.03.2004 ел №23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, карар чыгарам:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Сез 2020 елда Чубар-Абдул авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү, 2 төркем инвалидлар өчен 150 (50%) сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметергә һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- юлларга щебенка җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү) Чубар Абдул авылында Совет урамы, тыкры к- Совет урамынын 103 йортынан Чапаев урамынан 22 йортка кадәр, тыкрык Совет урамынын 115 нче йортынан Чапаев урамының 33 йортка кадәр., Буралы авылы, Октябрь урамы, Мәктәп урамы.

- Мәндәй авылы зиратын коймалау;

- бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (Яңа ел, Җиңү көне, Сабантуй, Халыкара өлкәннәр көне)

- Чубар-Абдул, Буралы, Мәндәй, Митрафан авылларында урам исемнәре язылган табличкалар ясату;

ӘЙЕ ЮК».

2. Әлеге карар түбәндәге чаралар аша халыкка игълан ителергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Чубар Абдул авылы, Совет урамы, 85 нче йорт,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Буралы авылы, Октябрь урамы, 34 нче йорт авыл мәдәният йорты,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Мәндәй авылы, Ялантау ур., 36б йорт, авыл мәдәният йорты янында урнашкан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында;

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Башлык: Н. Ә. Фәтхетдинов